**СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**
**«19» март 2020 ел** **№ 366**

**Биектау муниципаль районы Советының 2017 нче елның 16 нчы февралендәге 122 нче номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы муниципаль учреждениеләре тибын үзгәртү юлы белән төзелә торган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының муниципаль казна учреждениеләрен раслау турындагы» карарына үзгәрешләр кертү турында**

2003 нче елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турындагы», 2008 нче елның 25 нче декабрендәге 273-ФЗ номерлы «Коррупциягә каршы тору турындагы» Федераль законнары, Татарстан Республикасының 2004 нче елның 28 нче июленнән 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турындагы» Законы нигезендә, Биектау муниципаль районы Уставына таянып, Биектау муниципаль районы Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Биектау муниципаль районы Советының 2017 нче елның 16 нчы февралендәге 122 нче номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы муниципаль учреждениеләре тибын үзгәртү юлы белән төзелә торган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының муниципаль казна учреждениеләрен раслау турындагы » (Советның 28.03.2018 N 208, 29.10.2018 N 257, 14.12.2018 N 268, 17.04.2019 № 292 Карарлары редакциясендә) карары белән расланган «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы» муниципаль берәмлегенең муниципаль казна учреждениесе турындагы Нигезләмәсенең 1 нче кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6.6. пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутат, җирле үзидарәнең сайлаулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайлаулы вазыйфаи заты түбәндәгеләргә хокуклы түгел:

1) шәхсән яисә ышанычлы затлар аша эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шөгыльләнергә;

2) түбәндәге очраклардан тыш, коммерцияле яисә коммерциягә карамаган оешма белән идарә итүдә катнашу:

а) сәяси партия белән, профессиональ союз органы белән, шул исәптән җирле үзидарә органында муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән профсоюз оешмасының беренчел сайлаулы органы белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу, башка җәмәгать оешмасының, торак, торак-төзелеш, гараж

ширкәтләре, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәте съездында (конференциядә) яки гомуми җыелышларында катнашу;

б) коммерциягә карамаган оешма идарәсендә (сәяси партия белән идарә итүдә катнашудан тыш, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайланулы органы, Россия Федерациясе субъекты законында билгеләнгән тәртиптә Россия Федерациясе субъектының югары вазыйфаи затына (Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесенә) алдан хәбәр итеп, башка иҗтимагый оешманың съездында (конференциясендә) яисә гомуми җыелышында, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларында, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтендә катнашудан тыш) катнашу;

в) Россия Федерациясе субъекты муниципаль берәмлекләре советында, муниципаль берәмлекләрнең башка берләшмәләрендә, шулай ук аларның идарә органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә күрсәтү;

г) оешма учредителе вәкаләтләрен яки муниципаль милектәге акцияләр (устав капиталы өлешләре) белән муниципаль берәмлек исеменнән идарә итү тәртибен билгели торган муниципаль хокук актлары нигезендә учредителе (акционеры, катнашучысы) муниципаль берәмлек булган идарә органнарында һәм ревизия комиссиясендә муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә белдерергә;

д) федераль законнарда каралган башка очраклар;

3) Укытучылык, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлектән тыш, башка түләүле эшчәнлек белән шөгыльләнергә. Шул ук вакытта әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә яисә Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса, укытучылык, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлек бары тик чит дәүләтләр, халыкара һәм чит ил оешмалары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар акчалары исәбеннән генә финанслана алмый;

4) Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә яисә Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса, коммерциячел булмаган хөкүмәтнеке булмаган чит ил оешмалары идарә органнары, попечительләр яисә күзәтү советлары, һәм Россия Федерациясе территориясендә эшләүче аларның структур бүлекчәләре составына керергә.

2) 6.6 пунктының 6.1 пунктчасын төшереп калдырырга;

3) түбәндәге эчтәлектәге 6.6.1. – 6.6.6 пунктлары белән тулыландырырга:

«6.6.1. Депутат, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон һәм башка федераль законнар белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны, бурычларны үтәргә тиешләр. Депутатның, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасының, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затының вәкаләтләре «Коррупциягә каршы көрәш турындагы» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт Вазыйфаларын биләүче затлар һәм аларның керемнәренә башка затлар чыгымнарының туры килүен тикшереп тору турындагы» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон, «Аерым категориядәге затларга Россия

Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм булдыруны, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны тыю турындагы» 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән вазыйфаларны үтәмәгән очракта, вакытыннан алда туктатыла, әгәр әлеге Федераль закон белән башкасы каралмаган булса.

6.6.2. Депутат, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты тарафыннан коррупциягә каршы көрәш турында Россия Федерациясе законнары нигезендә тапшырыла торган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү Татарстан Республикасы законы белән билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасының югары вазыйфаи заты (Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесе) карары буенча уздырыла.

6.6.3. Әлеге Нигезләмәнең 6.6.2 пункты нигезендә уздырылган тикшерү нәтиҗәсендә «Коррупциягә каршы көрәш турындагы» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда, «Дәүләт Вазыйфаларын биләүче затлар һәм аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турындагы» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законда, «Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм булдыруны, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, финанс инструментларыннан файдалануны тыю турындагы» 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль законда каралган чикләүләрне, тыюларны һәм вазыйфаларны үтәмәү фактлары ачыкланган очракта, Татарстан Республикасының иң югары вазыйфаи заты (Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органы җитәкчесе) депутат, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затының вәкаләтләрен алдан туктатуы турында яки күрсәтелгән затларга карата башка җаваплылык чарасы куллану турында тиешле карар кабул итәргә вәкаләтле җирле үзидарә органына яки судка гариза белән мөрәҗәгать итә.

6.6.4. Үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр тапшырган җирле үзидарә органының сайланулы вазыйфаи затына, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр биргән депутатка, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына, әгәр бу белешмәләрне бозу җитди булмаса, түбәндәге җаваплылык чаралары кулланылырга мөмкин :

1) кисәтү;

2) депутатны, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасын аның вәкаләтләре срогы тәмамланганчы, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органында, җирле үзидарәнең сайланулы органында вазыйфалар биләү хокукыннан мәхрүм итеп, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органында, җирле үзидарәнең сайланулы органында вазыйфасыннан азат итү;

3) даими нигездә вәкаләтләрне гамәлгә ашырудан аның вәкаләтләре срогы туктатылганчы даими нигездә вәкаләтләр башкару хокукыннан мәхрүм итеп азат итү;

4) муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органында, җирле үзидарәнең сайланулы органында аның вәкаләтләре срогы туктатылганчы вазыйфалар биләүне тыю;

5) вәкаләтләре срогы туктатылганчы даими нигездә вәкаләтләр башкаруны тыю.

6.6.5. Депутатка, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына карата әлеге Нигезләмәнең 6.6.4 пунктында күрсәтелгән җаваплылык чараларын куллану турында карар кабул итү тәртибе Татарстан Республикасы законы нигезендә муниципаль хокукый акт белән билгеләнә.

6.6.6. Муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр Биектау муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла һәм (яисә) массакүләм мәгълүмат чараларына муниципаль хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгару өчен тапшырыла.

2. Әлеге карарны Биектау муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ адресы буенча һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында: http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча урнаштырып халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Биектау муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе, җирле үзидарәләр һәм җәмәгатьчелек белән элемтәләр буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совета рәисе,
Район Башлыгы Р.Г.Кәлимуллин